**Яр Чаллы шәһәренең “Акчарлак” 32 нче катнаш балалар бакчасы”
муниципаль автономияле мәктәпкәчә белем бирү
учреждениесе**

# Сценарий темасы:
# “*Кар бабай балаларда кунакта*”
**2 нче кечкенәләр төркеме өчен**

**Тәрбиячеләр:
Андерьянова Эльмира Рифгатовна,
Хасанова Айгөл Сафуановна.**

**Яр Чаллы
2025 ел.**

***Балалар залга керәләр. ( «В детский сад пришли сегодня наши малыши» музыкасы астына)***
Балалар тәрбиче белән бер-бер артлы залга керәләр.
**А.б.:** Бүген чыршы янында
Әйлән-бәйлән уйнарбыз.
Кыш бабайны каршыларбыз
Яңа җырлар җырларбыз.
Нинди матур безнең чыршы
Җем-җем итеп яна ул.
Башлыйбыз чыршы бәйрәмен
Котлы булсын яңа ел.

**Җыр "Чыршыкай "**

Мәдинә:Бүлмәдә чыршы агачы:
Ул яшелдән киенгән.
Чыршы да урманнан безгә
Бәйрәм итәргә килгән.

Рамзан: Уенчыклар белән аны
Бизәдем төрле төскә.
Кызыл йолдыз ясап куйдым
Балкысын өчен өскә.

**Сәмия:** Бәйрәм җиткәнен чыршы
Кайлардан гына белгән.
Энәле күлмәген кигән дә
Безгә кунакка килгән.

Азамат:Здравствуй наша ёлочка,
Здравствуй Новый год!
У ёлки дружно встанем
В весёлый хоровод.

Ясминә:Новый год, новый год,
В двери постучится,
Будет праздник у нас,
Будем веселиться!

***Әмир:***Ёлочка красивая,
Ёлочка густая,
На пушистых веточках
Бусинки сверкают!
**А.б.:** Чыршы да бүген безгә кунакка килгән, уенчыклар,шарлар белән бизәлгән. Яңа ел белән котлыйбыз,шатлык килсен һәр өйгә! Килгән кунакларны котларбыз: сәламәтлек , бәхет теләрбез!

**Җыр «Чыршы янында биибез»**

***Балалар урындыкларга утыралар***

**А.б.:** Кемдер килә ахры,әйдәгез, кул чабып каршы алыйк. Безне күрми китмәсеннәр!

(балалар кул чаба)

***Музыка астында Кар кызы керә.***

**Кар кызы:**Исәнмесез, дусларым,
Килдем сезгә кунакка.
Сагындым дусларымны:
Зурларны һәм нәниләрне.
Җитезләрне һәм өлгерләрне.

Мин Кар кызы,мине балалар,таныйсыздыр.Мин салкын карларны,җил-бураннарны яратам. Кая сез көмеш Кар бөртекләре? Чыгыгыз тизрәк минем янга! Чыршыбыз аллы- гөлле утлары белән балкып торсын.

***Балалар чыгып шигырь сөйлиләр(султанчиклар өләшәбез)***

**С.Раян:** Әйдәгез, дуслар,
Кошларны саклыйк.
Һәрбер агачка
Җимлекләр ясыйк.

***Фәизә:*** А на варежке одна
Чудо-звёздочка видна-
Снежная крупинка:
-Здравствуй я снежинка!

***Зәлинә:***Тәрәзәгә күз салдым
Тордым да бүген иртән.
Күргәч аптырап калдым:
Җирне кем ап-ак иткән?

***Кар кызы белән бию «Кар бөртекләре биюе»***

**А.б.:** дусларым, бик матур биедегез.
Тыңлагыз ,тавышланмагыз. Тыныч кына утырыгыз! Ишетәсезме, кар шыгырдый, кемдер безгә ашыга.

**Кар бабай керә ( под музыку «Поселился снеговик во дворе»)** ***себерке һәм чиләк тоткан.***

**Кар бабай:**Исәнмесез, дусларым! Менә килеп җиттем мин дә. Күпме сукмаклар,юллар уздым һәм менә ниһаять, сезнең бакчага килеп җиттем. Ясандым,тырыштым. Чиләгемне киеп алдым,кишердән борын куйдым. Һәркем белеп торсын, мин булырмын Кар бабай.
Уйнарга мин бик яратам,җырларга һәм биергә! Үзем белән кар йомарламнары алдым, уйныйбызмы дусларым? Кар йомарламнарын җыеп уйнап алабызмы?

**(чиләгендәге кар йомарламнарын чәчеп җибәрә) .**

***Уен "в снежки"***

**А.б.:** Кар йомарламнары салкын була,күп уйнасаң,кулларың туңар.

**Кар бабай:**Кулларымны чәбәклим!(чәбәкли)

Аякларым белән тыпырдыйм!(тыпырдый)
Бәйрәмне дәвам итик,
Бергәләп биеп алыйк.

***«  Без җылынабыз»-(Снег-снежок)***

***Уен тәмамлангач,балалар урыннарына утыралар.***

-Минем монда күңелсез хәл. Карагыз әле  миңа! ( Кар бабай бияләен битеннән ала, борыны- кишере юкка)

**Кар кызы:**Кар бабай, син борыныңны югалткансың ахры!

*кар бабай авыр сулап куя,күз яшьләрен сөртә.*

**А.б.:** Борчылмагыз! Без,балалар белән,борыныңны табарга булышырбыз.

**Кар бабай:**Балалар, карагыз әле,бәлки минем борыным берәрегезнең кесәсендә ятадыр? (балалар карыйлар,ләкин тапмыйлар) Ә урындык астында юкмы соң? (эзлиләр)

**Кар кызы:**Кем ярдәм итә алачагын мин беләм! Әйдәгез,тизрәк Кыш бабайны чакырыйк!

-Кыш бабай!(чакыралар)

**Кыш бабай:** Ау! Ау!Киләм-киләм!!
Исәнмесез, дусларым! Яңа ел белән сезне!
Үскәнсез, зур малайлар,зур кызлар булгансыз!
Ә сез мине таныдыгызмы? Кем соң мин?
Яңа еллар белән сезне котлыйм, дусларым. Ягез әле,чыршы тирәли әйләник.Бәйрәмебезне тагы да күңеллерәк итик!

**Кар кызы:**Кыш бабай,ә безнең чыршыбызның утлары янмый бит!

**Кыш бабай:** Ай-яй, нинди тәртипсезлек бу. Ярамый болай! Хәзер төзәтәбез без аны! Ә сез,дусларым,миңа ярдәм итәрсез. Тылсымлы сүзләрне бергә кабатларга кирәк:
«Бер,ике,өч!Чыршыкай,утларыңны кабызчы!»

***Чыршы утлары кабына***

**Кыш бабай:** Ииих, ак сакалым! Әгәр мин монда килгәнмен икән,күңелле уеннар,җырлар,биюләр булырга тиеш!Түгәрәккә басыгыз, Яңа елны каршылыйк.

***Чыршы тирәли түгәрәккә басалар.***

**Хоровод «Кыш бабай белән күмәк җыр ».**

**Кыш бабай:** Мин инде бик карт,балалар. Күп-күп еллар мин туганга.Бәйрәмгә килсәм,онытыла барсы да. Тизрәк уйныйсы килә башлый сезнең белән. Әйдәгез,уйнап алыйк әле.

**Уен: "Өшетәм"**

**Кыш бабай:** -Хәзер мин сезнең битләрегезне чеметәм.
-Хәзер кытыклыйм.
-Хәзер борыннарыгызны өшетәм.

**Уен «Куып тотам» (на мел. « Мы бежим Мороза догонять»)**

**Кыш бабай:** (в конце пляски) Ух,мин сезне хәзер куып тотам!
(Кыш бабай куа,балалар йөгерәләр)

**Кыш бабай:** Ох,балалар,сез булдырдыгыз!Бабагыз белән шәп уйнадыгыз.

*Балалар утыралар.*

***Кар бабайны күреп ала.***

**Кыш бабай:** Кар бабай,ни булды сиңа? Нишләдең син,кая куйдың борыныңны?

***Кар бабай җилкәләрен селкетә,авыр сулый.***

**Кар кызы:**Кыш бабай,булышыйк әле Кар бабайга.Аның борыны югалган. Без балалар белән эзләп- эзләп карадык,таба гына алмадык. Ә менә син ярдәм итә алырсың дип уйлыйм.

**Кыш бабай:** Борын?...Моны уйлап карарага кирәк !(башын кашып ала) Ничек кенә ярдәм итәргә соң сезгә? Белмим дә. Шулай да бер сере бар инде аның.

Куяннарга хәбәр салсак,алар бик тиз кишерләр алып килерләр иде. Куянкайлар чыгыгыз. Чыршы янынды биеп алыгыз!

**Бию «Куяннар »** *Кәрзиннән кишерләр өләшенә. Биюдән соң җыеп алына.*

**Кыш бабай:** Менә күпме кишер!!Мә,ал сайлап,Кар бабай үзеңә кишер борыныңа! (*Кар бабай борынын кияргә китә)*

**А.б.:** Безнең балалар син килүгә матур шигырьләр өйрәнделәр бит ,бабакай!

**Шигырьләр:**

**Айсылу:**Бөтен җирдә ак юрган...
Белдем-белдем — кар яуган!
Әй шәп булган, шәп булган —
Без шуарбыз таулардан.

**Мәдинә:** Урамда буран
Мин өйдә торам
Тәрәзә аша
Тик авыз ерам

**Рияз:** Яңа елга бүләк алып
Кыш бабай килде.
Бакчадагы һәр балага
Бүләкләр бирде.

**Рания :** Кар кызы да яңа елга
Кунакка килгән.
Кыш бабай бездә икәнен
Ул каян белгән.

**Г.Раян:** Рәхмәт сиңа, Кыш бабай,
Безнең белән дус бабай,
Сагынып килеп җиттең,
Яңа ел бүләк иттең.

**Ильназ:** Берәр яшькә үстердең,
Һәммәбезгә көч бирдең,
Рәхмәт сиңа, Кыш бабай,
Безнең белән дус бабай!

**Риана:** Кыш бабай килә җилдереп,
Капчык кулында.
Кар бураннар тузып кала
Аның юлында.
**Мәрьям:** Дед Мороз хороший
Хлопает в ладоши,
В валенках шагает,
Ёлку зажигает!
**Азалия:** Менә нинди кар яуды:
Ап-ак булды җир өсте.
Чаналарга, чаңгыларга
Җиткереп булмый эшне.
**Рамзан:** Добрый Дедушка Мороз,
Он подарки нам принес.
На оленях прилетел,
К нам на праздник он успел!

**Адель:** Возле елочки - подарки,
Вокруг елки - хоровод.
До чего же праздник сладкий
Этот славный Новый год.

**Кар бабай:** (борынын киеп куя): Рәхмәт сиңа, Кыш бабай! Рәхмәт, куянкайлар! Рәхмәт сезгә,дусларым! Нинди матур минем борыным! Күңелләрем күтәрелеп китте,уйныйсым килеп китте. Урындыклардан тордык, күңелле биюгә чыгыйк.
**Бию «Парлы..»**
**Кыш бабай**: Залда кызу булып китте! Салкын су булса иде,эри башладым ахры.
**Кар бабай:**Хәзер- хәзер Кыш бабай! (су артыннан китә)
**Кыш бабай:** Утырып торыйм булмаса.
*Кар бабай керә. Чанасында чиләк белән чашка.*
*(бутафор)*
**Кар бабай:**Салкын су эчеп җибәр әле, Кыш бабай!
**Кыш бабай:** Рәхмәт,Кар бабай!
Кыш бабай чиләктән су алып эчә дә ,чашкасын селтәп җибәрә,кәнфит килеп төшә.
**Кар бабай:**Ой, кыш бабай,нәрсә ул анда ,синең чашкаңда?
**Кыш бабай:** Яңа елда тылсымлы хәлләр була шулай.Хыяллар чынга аша.Хәтта, гади су да яңа ел бүләкләренә әйләнә.
**Кар кызы:**(чиләккә күз сала):Ой, ә монда чыннан да, балаларга бүләкләр! Ай,Кыш бабай,син хәйләкәр,җитмәсә әле тылсымга да бай.
**Кыш бабай:** Мин шаян Кыш бабагыз! Барыгызга да бүләкләр алып килдем!

*Бүләкләр өләшәбез.*